ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

14.10.2022 | с. Коргуза | 02

Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы Татарстан Республикасы Законының 35нче ст., Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 31 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешәсезме:

- Патрикеево авылында урамнарны яктырту һәм исәпкә алу узелларын урнаштыру

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Кибет бинасы янында гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Патрикеево ав., 3әя ур., 50 й. 11.00 сәг.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В.Плохов